**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5434**
**20.08.2024**

Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның
400 еллыгына багышланган «Сувенир-бренд»
юбилей символикасы белән иң яхшы
сувенир продукциясе үрнәгенә ачык шәһәр
конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәре символикасы белән сувенир продукциясен популярлаштыру, шулай ук җирле товар җитештерүчеләрнең продукциясен алга чыгару максатында һәм Башкарма комитетның 2023 елның 2 октябрендәге 9357 номерлы Карары белән расланган «2024-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган «Сувенир-бренд» юбилей символикасы белән иң яхшы сувенир продукциясе үрнәгенә ачык шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) әзерләү һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 20 августындагы
5434 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган «Сувенир-бренд» юбилей символикасы белән иң яхшы сувенир продукциясе үрнәгенә ачык шәһәр конкурсын үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган «Сувенир-бренд» юбилей символикасы белән иң яхшы сувенир продукциясе үрнәгенә ачык шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели (алга таба – конкурс).

2. Конкурсны оештыручы булып Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тора.

3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсны үткәрү тәртибен аңлата;

2) конкурста катнашучыларның заявкаларын кабул итә;

3) конкурсның эксперт советын формалаштыра;

4) конкурста катнашучыларның исемлеген раслый.

4. Төп төшенчәләр:

1) шәһәр сувениры — төп истәлекле урыннарны чагылдыра, Яр Чаллы шәһәре белән ассоциацияләнә торган эшләнмә;

2) иң яхшы гастрономия сувениры:

- әлеге эчемлекнең тарихи барлыкка килгән җирле рецепты булуын һәм/яки аны әзерләгәндә җирле чималны төп ингредиент сыйфатында куллануны исәпкә ала торган тиешле документлары булган эчемлек (куас);

- әлеге продуктның тарихи барлыкка килгән җирле рецепты булуын һәм/яки аны әзерләгәндә җирле чималның төп ингредиент сыйфатында кулланылуын исәпкә ала торган тиешле документлары булган азык-төлек продукты (ризык: чәк-чәк, кәләвә, бавырсак, казылык, каз һәм башкалар);

3) текстиль сувенир — түбәтәй, кепка, футболка, милли курчак, милли кием һәм башкалар;

4) сувенир уенчык — агачтан һәм башка төр үсемлек чималыннан, керамикадан, металлдан, таштан, балчыктан, текстильдән, пластмассадан, катыргыдан, кәгазьдән, эрләгән җептән эшләнмәләр һәм башкалар;

5) полиграфик сувенир — каләм, блокнот, китап, календарь, значок, открытка, шәһәр турында фотоальбом һәм башкалар, кәгазьдән, катыргыдан ясалган эшләнмәләр һәм башкалар.

2 бүлек. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

5. Конкурсның максатлары:

1) халыкның сәнгать кәсепчелеген һәм һөнәрчелеген торгызу һәм үстерү;

2) халык һөнәрчелеге осталары профессиясенең абруен күтәрү;

3) үзебезнең сувенир продукциясе базарын үстерү.

6. Конкурсның бурычлары:

1) Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган, социаль-икътисадый казанышларны, тарихи-мәдәни традицияләрне, шәһәрнең кунакчыллыгын чагылдыра торган сувенир продукциясенең иң яхшы үрнәкләрен ачыклау;

2) тәҗрибә уртаклашу һәм барлык кызыксынган якларның үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен мәгълүмат һәм коммуникация мәйданчыклары булдыру;

3) сувенир продукциясе җитештерүче иң яхшы компанияләрне һәм осталарны ачыклау, иҗади инициативаларга ярдәм күрсәтү;

4) сувенир продукциясен эшләүгә һәм ясауга иң яхшы эшләр авторларын үзара хезмәттәшлеккә кызыксындыру;

5) базарны сыйфатлы һәм арзан бәядән сувенир продукциясе белән баетуга булышлык итү;

6) сувенирларның төрле вариантлары коллекциясен формалаштыру һәм киләчәктә аларны юбилей һәм вәкиллек чараларында куллану.

## 3 бүлек. Конкурс номинацияләре

7. Конкурска түбәндәге номинацияләрдә эшләнмәләр кабул ителә:

1) Шәһәр сувениры;

2) Иң яхшы гастрономия сувениры;

3) Текстиль сувенир;

4) Сувенир уенчык;

5) Полиграфия сувениры.

## 4 бүлек. Конкурсның эксперт советы

8. Конкурсның эксперт советы конкурс эшләрен объектив сайлап алуны, аларны алга таба бәяләүне һәм конкурсның һәр номинациясе буенча җиңүчеләрне билгеләү максатларында төзелә. Эксперт советы составына сувенир продукциясе, декоратив-гамәли иҗат һәм һөнәрчелек, маркетинг, мәдәният өлкәсендәге экспертлар, шулай ук эшчәнлекнең башка өлкәләре белгечләре керә.

Конкурс эшләрен бәяләү эксперт советы тарафыннан 10 баллы система буенча түбәндәге критерийлар буенча гамәлгә ашырыла:

1) тиешле номинациягә туры килү;

2) башкаруның оригинальлеге;

3) эстетик күренеш;

4) тиражлауның технологияле һәм гади булуы;

5) презентабельлек;

6) башкаруның катлаулылыгы.

Берничә катнашучының эшен тигез бәяләгәндә, эксперт советы рәисенең тавышы хәлиткеч була.

9. Эксперт советы карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, эксперт советы рәисе тарафыннан имзалана, карар катгый булып санала һәм яңадан каралырга тиеш түгел.

## 5 бүлек. Конкурсны уздыру тәртибе

10. Конкурс ике этапта уздырыла:

1) беренче этап 2024 елның 5 сентябреннән 2024 елның 31 декабренә кадәр түбәндәге электрон почтага конкурс эшләренең фото һәм видеоматериалларын җибәрү юлы белән үткәрелә: economica.chelny@yandex.ru;

2) икенче этап — 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 3 февраленә кадәр. Конкурс эшләрен кабул итү эксперт советы сайлап алган эшләрнең беренче этабы йомгаклары буенча гамәлгә ашырыла. Конкурс эшләре Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 106 кабинет адресы буенча Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә тапшырыла. Тел. 8(8552) 30-55-12, 8(8552) 30-58-21, эш көннәрендә 08.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр.

11. Конкурста катнашуга нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә гариза биргән юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр, сувенир продукциясен әзерләүдә һөнәри осталар, нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык биргән коммерцияле булмаган оешмалар чакырыла.

Конкурста катнашкан өчен теркәлү взносы алынмый.

## 6 бүлек. Конкурс эшенә таләпләр

12. Конкурста бәяләү предметы булып Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган юбилей символикасы төшерелгән, теләсә нинди техникада, теләсә нинди жанрда, теләсә нинди төсләр гаммасында башкарылган сувенир тора:

1) конкурс эшенең күләме 50 см дан артмаска тиеш;

2) конкурска шәхси авторлык эшләре яисә берничә авторның эшләре тәкъдим ителергә мөмкин;

3) конкурс эше нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә мәгълүмат этикеткасы белән тәэмин ителергә тиеш;

4) һәр катнашучы сувенирларның берничә вариантын тәкъдим итә ала;

5) конкурс эше конкурсант катнаша торган конкурс номинациясенә туры килергә тиеш;

6) конкурс эшендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми символикасын: Яр Чаллы шәһәренең гербын һәм флагын куллану, шәһәр үсеше тарихының төп этапларын, мәдәни-рухи традицияләрне, юбилей шигарьләрен, шәһәр территориясендә яшәүче халыкларның орнамент элементларын, территориянең табигый үзенчәлекләрен чагылдыру рөхсәт ителә.

Конкурс шартларына һәм тематикасына туры килми торган, әлеге нигезләмә таләпләрен бозып эшләнгән конкурс эшләре каралмый.

## 7 бүлек. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү

13. Бүләкләү түбәндәгеләрне тапшырып үткәрелә:

1) I дәрәҗә диплом — һәр номинациядә кыйммәтле бүләк тапшырыла;

2) II дәрәҗә диплом — һәр номинациядә кыйммәтле бүләк тапшырыла;

3) III дәрәҗә диплом — һәр номинациядә кыйммәтле бүләк тапшырыла;

4) һәр катнашучыга «Катнашканы өчен» дипломнары тапшырыла.

14. Сувенир продукциясенең иң яхшы үрнәкләре авторлары белән киләчәктә аларны юбилей һәм вәкиллек чараларында куллану максатларында, сувенирлар партиясен әзерләүгә килешүләр төзелергә мөмкин.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган «Сувенир-бренд» юбилей символикасы белән иң яхшы сувенир продукциясе үрнәгенә ачык шәһәр конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган «Сувенир-бренд» юбилей символикасы белән иң яхшы сувенир продукциясе үрнәгенә ачык шәһәр конкурсында катнашуга
ЗАЯВКА

| | |
|---|---|
| Конкурста катнашучының исеме, Ф.И.А.и. | |
| Почта адресы, кәрәзле телефоны | |
| Тиешле номинация. Эшнең исеме | |
| Эшнең кыскача тасвирламасы (эшләнмәнең үлчәме, этикеткасы булу, шәһәрнең рәсми символикасын куллану һәм башкалар) | |
| Башкару техникасы | |
| Сувенир продукциясенең бәясе | |

Әлеге конкурста катнашып, мин авторлык һәм катнаш хокукларны саклауга җаваплылыкны үз өстемә алам.

Конкурста катнашу кагыйдәләре белән таныштым һәм ризалыгымны бирәм.

Дата Имза Ф.И.А.и.

Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган «Сувенир-бренд» юбилей символикасы белән иң яхшы сувенир продукциясе үрнәгенә ачык шәһәр конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

ПЕРСОНАЛЬ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК

Мин, ______________________________________________________________________

(персональ мәгълүматлар субъектының Ф.И.А.и.)

______________________________________________________________________________

(персональ мәгълүматлар субъектының адресы)

______________________________________________________________________________

(шәхесне раслаучы төп документның исеме, сериясе, номеры, бирелгән вакыты, кем тарафыннан бирелгән)

Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган «Сувенир-бренд» юбилей символикасы белән иң яхшы сувенир продукциясе үрнәгенә ачык шәһәр конкурсында катнашучы буларак, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Әлеге ризалык аны имзалаган вакыттан соң үз көченә керә һәм конкурс үткәрү тәмамланганга кадәр гамәлдә була.

«___»_________20___ _______________ _______________

(имза) (Ф.И.А.и.)

Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгына багышланган «Сувенир-бренд» юбилей символикасы белән иң яхшы сувенир продукциясе үрнәгенә ачык шәһәр конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

ЭТИКЕТКА

Конкурста катнашучының исеме, Ф.И.А.и. (тулысынча) ______________________________

________________________________________________________________________________

Эшнең исеме ________________________________________________________________

Эшнең тасвирламасы
_________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Конкурска тапшырылган эшләнмәнең бәясе _____________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Һәр төргә этикетка/сувенир продукциясенең һәр данәсе аерым тутырыла, ул беркетелгән булырга тиеш.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И.Галиева